**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы**
**КАРАРЫ**

**2020 елның 28 декабре** **№ 24**

**«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты турында» 2019 елның 16 декабрендәге 236 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында** (2020 елның 22 июнендәге 257 номерлы, 2019 елның 07 сентябрендәге 272 номерлы карарлар редакциясендә)

«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, шулай ук муниципаль район Уставының 92 статьясына һәм Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2013 елның 18 декабрендәге 201 номерлы карары белән расланган Кама Тамагы муниципаль районындагы бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты турында» 2019 елның 16 декабрендәге 236 номерлы карарын түбәндәге редакциядә чыгарырга:

«1 статья

1.2020 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының фаразланучы керемнәрнең гомуми күләме 554252,4 мең сум ;

2) Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 589697,6 мең сум.

3) Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты кытлыгы 35445,2 мең сум күләмендә.

2. 2021 һәм 2022 план чорына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы бюджетының төп характеристикаларын расларга.

1) 2021 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының фаразланган гомуми керем күләме 4569,22 мең сум һәм 2022 елга 463142,79 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының 2021 елга чыгымнарының гомуми күләме 456969,22 мең сум , шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 9195,0 мең сум күләмендә, 2022 елга 463142,79 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 18690,0 мең сум

күләмендә.

3) 2021 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының бюджет кытлыгы 0 мең сум һәм 2022 елга 0 мең сум күләмендә.

3. 2020 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, 2021 һәм 2022 нче елларның план чорына 2 нче кушымта нигезендә расларга.

2 статья

1. 2021 елның 1 гыйнварына кадәр расларга:

- Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиге 0 мең сум күләмендә.

2. 2022 елның 1 гыйнварына булган мәгълүматлар буенча расларга:

- Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиге 0 мең сум күләмендә.

3. 2023 елның 1 гыйнварына кадәр расларга:

- Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль эчке бурычының иң югары чиге 0 мең сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке муниципаль бурычның иң югары чиге 0 мең сум күләмендә.

4. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының 2020 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән мөмкин булган гарантия очраклары буенча муниципаль гарантияләрне үтәүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 0,0 мең сум, 2021 елга 0,0 мең сум һәм 2022 елга 0,0 мең сум күләмендә расларга.

3 статья

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетында 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына фаразланган керем күләмен әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга .

5 статья

1. Акцияләре Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы

җирле үзидарә органнары милкендә булган акционер җәмгыятьләрнең идарә органнары (директорлар советы, күзәтү советы, акционерларның гомуми җыелышы) тарафыннан чиста табыштан файдалану һәм дивидендлар түләү мәсьәләләре буенча карарлар кабул иткәндә, акцияләре 2020 елның 1 сентябренә кадәр акцияләр буенча дивидендлар түләү өчен ел нәтиҗәләре буенча чиста табышның 30 процепттан да ким булмаган күләмдә тавыш бирергә тиеш.

2. 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре табышының 2019 ел йомгаклары буенча салымнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләгәннән соң кала торган өлешен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетына күчерү 2020 елның 1 июленә кадәр әлеге керемнең 30 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

6 статья

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген, әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген, әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә расларга.

7 статья

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне расларга

1) 2020 елга әлеге Карарга 7 нче кушымта нигезендә;

2)2021 һәм 2022 еллар план чорына әлеге Карарга 8 нче кушымта нигезендә .

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

1)2020 елга әлеге Карарга карата 9 нчы кушымта нигезендә ;

2)2021 һәм 2022 елларның план чорына әлеге Карарның 10 нчы кушымтасы нигезендә.

3. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялары (Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Карарга 11 нче кушымта нигезендә расларга .

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2020 елга 734,0 мең сум, 2021 елга 1267,0 мең сум һәм 2022 елга 1295,0 мең сум күләмендә расларга.

8 статья

Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга - товар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы Карары белән билгеләнгән тәртиптә бирелә.

9 статья

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы җирлекләренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә муниципаль район бюджетыннан дотацияләр күләмен расларга:

1) 2020 елга - 27552,9 мең сум күләмендә,
2) 2021 елга 28444,69 мең сум күләмендә ,
3) 2022 елга 29353,09 мең сум күләмендә,

шул исәптән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән:

- шәһәр җирлекләре буенча 2020 елга-408,7 мең сум, 2021 елга-427,4 мең сум, 2022 елга-419,4 мең сум.;

- авыл җирлекләре буенча 2020 елга-54,8 мең сум, 2021 елга-57,7 мең сум, 2022 елга – 57,3 мең сум, әлеге Карарга 12 нче кушымта нигезендә бүленеп бирелә.

10 статья

1. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен расларга:

- хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча 2020 елга 1996,1 мең сум, 2021 елга 1890,3 мең сум, 2022 елга 1919,9 мең сум, әлеге Карарга 13 нче кушымта нигезендә ;

- гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча 2020 елга 1,0 мең сум, 2021 елга 1,0 мең сум, 2022 елга 1,0 мең сум, әлеге Карарның 14 нче кушымтасы нигезендә бүлеп бирелә.

11 статья

1.Төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетына җирлекләр бюджетларыннан күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен исәпкә алырга:

1) «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды чаралары хисабына финанс ярдәме алу өчен Кама Тамагы муниципаль районы бюджетында күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен ел саен 2020-2022 елларга 1711,0 мең сум акчаны әлеге Карарга 15 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

2) «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында».2011 елның 7 декабрендәге 6-ФЗ Федераль законны үтәү йөзеннән, 2020 елга тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча

255,0 мең сум, 2021 елга 259,0 мең сум, 2022 елга 273 мең сум, әлеге карарның 16 нчы кушымтасы нигезендә.

3) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән Кама Тамагы муниципаль районы бюджетында 2020 елга 1693,2 мең сум, 2021 елга 1365,2 мең сум һәм 2022 елга 1340,6 мең сум күләмендә авыл җирлекләре бюджетларыннан ял оештыру һәм җирлек халкын мәдәният учреждениеләре хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруга тапшырыла торган бюджетара трансфертлар әлеге карарга 17 нче кушымта нигезендә.

2.Тиешле җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына җирлекләр бюджетларында әлеге статьяда күрсәтелгән бюджетара трансфертларны алдан исәпкә алырга кирәк.

3., 2020 елда Кама Тамагы муниципаль районы бюджетына җирлекләр бюджетларыннан 2020 елның 1 маена кадәр бюджетара трансфертларның еллык күләменең кимендә 1/2 өлеше күләмендә һәм 2020 елның 1 октябренә кадәр калган калган өлеше бюджетара трансфертларның калган өлеше күчерү күздә тотыла, дип билгеләргә.

12 статья

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алынучы бюджетара трансфертларны исәпкә алырга:

- 2020 елда әлеге Карарга 18 нче кушымта нигезендә 410240,6 мең сум күләмендә;

- әлеге Карарга 19 нчы кушымта нигезендә 2021 елда 310599,22 мең сум һәм 2022 елда 312331,74 мең сум күләмендә,

13 статья

1. 2020 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 16705,1 мең сум, 2021 елга 16800,0 мең сум күләмендә, 2022 елга 17700,0 мең сум күләмендә расларга һәм аларны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга 2020, 2021 һәм 2022 елларга җибәрергә.

13.1 статья.

Кама Тамагы муниципаль районы бюджетында муниципаль берәмлекләр бюджетларына 2020 елда муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә 250,8 мең сум күләмендә тапшырыла торган бюджетара трансфертларны әлеге Карарга 20 нче кушымта нигезендә расларга.

13.2 статья.

Кама Тамагы муниципаль районы бюджетында гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә муниципаль берәмлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертларны 13164,0 мең сум күләмендә расларга, әлеге Карарга 21 нче кушымта нигезендә.

13.3 статья.

Кама Тамагы муниципаль районы бюджетында авыл җирлекләренә территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә һәм грантлар бирүгә бюджетара трансфертлар, 2020 елда 7178,0 мең сум күләмендә бюджетара трансфертларны әлеге Карарга 22 нче кушымта нигезендә расларга.

13.4 статья.

Кама Тамагы муниципаль районы бюджетында башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан 2020 елда 8355,6 мең сум күләмендә кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен бюджетара трансфертларны әлеге Карарга 23 нче кушымта нигезендә расларга.

14 статья

2020 елда һәм 2021, 2022 елларның планлы чорында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына бюджет кредитлары бирелми дип расларга .

15 статья

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль хакимият органнары 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләре санын, шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль хакимият органнары, муниципаль казна учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2020 елда муниципаль хезмәткәрләр санын, шулай ук муниципаль хакимият органнары , муниципаль казна учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, бюджет өлкәсенең башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

16 статья

1. 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы исеменнән төзелгән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар суммасыннан файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты акчалары 2019 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар суммасыннан 2020 елда күрсәтелгән максатларга тиешле

бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетын үтәгәндә әлеге карар белән расланган кеœремнәрдән артык фактта алынган субсидияләр һәм субвенцияләр, әлеге карарга үзгәрешләр кертмичә генә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертмичә, субсидияләр һәм субвенцияләр бирү максатларына чыгымнарны арттыруга җибәрелә.

17 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

18 статья

Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.»

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы Н.А. Вазыйхов**